**СОВЕТ КУТЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Клубная, д.1а, село Кутема, 423112

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**КҮТӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Клуб урамы, 1а йорты, Күтәмә авылы, 423112

тел.+7(84396) 4-30-88, e-mail: Kut.Cmn2@tatar.ru

№ 91 15 сентябрь 2023 ел

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**Күтәмә авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 декабрендәге №117 «Күтәмә авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Күтәмә авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге № 286-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Күтәмә» авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 декабрендәге № 117 «Күтәмә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Күтәмә авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәне раслау хакында» карарының 1 кушымтасының 16 пунктының 2 абзацын (2021 елның 21 июнендәге № 26, 2022 елның 18 маендагы № 58 үзгәрешләре белән) яңа редакциядә бәян итәргә: «Муниципаль вазыйфаны биләүче затның үз чыгымнары турында белешмә бирмәве,

федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган мәгълүматлар бирүе, яисә үз чыгымнары турында белә торып дөрес булмаган мәгълүматлар бирүе яки хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балалары чыгымнары турында белешмәләр бирмәү, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган мәгълүмат тапшыру, яки хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белә торып дөрес булмаган мәгълүмат бирү, әгәр мондый мәгълүматны тапшыру мәҗбүри булса, гамәлдәге закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә аны биләгән вазифасыннан азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Күтәмә авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Н.Г. Сабиров